| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.08.2019 Алексеевск ш. т. б. № 362

**Татарстан Республикасы Алексеевск**
**муниципаль районы"4 нчеАлексеевск гомуми**
**белем бирү башлангыч мәктәбе"**
**муниципаль бюджетгомуми белем бирү**
**учреждениесендә түләүле хезмәтләр күрсәтү турында**

«Түләүле белем бирү хезмәтләре күрсәтү Кагыйдәләрен раслау турында» 2013 елның 15 августындагы 706 номерлы РФ Хөкүмәте Карары, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы карамагындагы дәүләт бюджет учреждениеләре эшчәнлегенең төп төрләренә керә торган хезмәтләр күрсәтүгә (эшләр башкаруга) түләүне билгеләүнең якынча тәртибен раслау турында» 2010 елның 30 декабрендәге 1170 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (үзгәрешләр белән) нигезендә, гражданнар һәм юридик затлар өчен), Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) белем бирү оешмалары тарафыннан физик (юридик) затларга күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында регламентны раслау хакында» 2014 елның 6 маендагы 2556/14 номерлы боерыгы нигезендә һәм “Алексеевск 4 нче башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе» ндә мәгариф өлкәсендә гражданнарның ихтыяҗларын канәгатьләндерү, хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатын яхшырту, хезмәт күрсәтүләрне үстерүне һәм камилләштерүне тәэмин итү өчен өстәмә финанслар җәлеп итү, матди-техник базасын киңәйтү максатларында

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «4 нче Алексеевск башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесендә түләүле хезмәт күрсәтүне оештырырга.

2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының “4 нче Алексеевск башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе “муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесендә түләүле хезмәтләр күрсәтү исемлеген раслау (1 нче кушымта)

3. 2019 елның 1 сентябреннән түләүле хезмәтләр күрсәтүгә бәяләр прейскурантын расларга (2 нче кушымта).

4. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының "Бюджет һәм Автоном учреждениеләренең бюджеттан тыш чаралары турында" 2016 ел, 30 декабрь, 21-53-24-3742 нче хаты нигезендә түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган акчаларны тоту тәртибен билгеләргә:

- матди-техник базаны ныгытуга чыгымнар-25%

- хезмәт өчен түләү билгеләү һәм хезмәт өчен түләү чыгымнары-75%,

5. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «4 нче Алексеевск башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директорына (Г. Н.Сөнгатуллина) гамәлдәге законнар нигезендә өстәмә түләүле хезмәтләр күрсәтү өчен шартлар тудырырга.

6.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Н.П. Чуринга йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Н.К. Кадыйров**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкармакомитетының
26.08.2019 ел 362 номерлы
карарына 1нче кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы "4 нче Алексеевск башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе»муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе буенчатүләүле хезмәтләр исемлеге**

| № т/б | Хезмәтнең атамасы | Хезмәт күрсәтүнең дәвамлылыгы |
|---|---|---|
| 1 | Санаудан чишелешкә кадәр | Атнага 2 тапкыр 30 ар минут |
| 2 | АБВГД-ка | Атнага 2 тапкыр 30 ар минут |
| 3 | Кулларны язуга әзерләү | Атнага 2 тапкыр 30 ар минут |
| 4 | «Акыл үстерү» | Атнага 2 тапкыр 30 ар минут |

**Башкарма комитетыныңэшләр идарәчесе** **Г. А. Йосыпова**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкармакомитетының
26.08.2019 ел 362 номерлы
карарына 2нче кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы "4 нче Алексеевск башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе»муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе буенчабер укучыга түләүле хезмәтләр күрсәтүгә бәяләр прейскуранты**

| № т/б | Хезмәтнең атамасы | Хезмәт күрсәтүнең айлык хакы (сум) | Хезмәт күрсәтүнең дәвамлылыгы |
|---|---|---|---|
| 1 | Санаудан чишелешкә кадәр | Ике йөз илле | Атнага 2 тапкыр 30 ар минут |
| 2 | АБВГД-ка | Ике йөз илле | Атнага 2 тапкыр 30 ар минут |
| 3 | Кулларны язуга әзерләү | Ике йөз илле | Атнага 2 тапкыр 30 ар минут |
| 4 | «Акыл үстерү» | Ике йөз илле | Атнага 2 тапкыр 30 ар минут |

**Башкарма комитетының эшләр идарәчесе Г. А. Йосыпова**